СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

24.09.2018 — с. Кильдеево — 46-219

Килди авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Килди авыл җирлеге Уставының 11 нче статьясы, Килди авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 45-216 нчы номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Килди авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 17 нче номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Килди авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны җирлюллау белән килешәсезме?:
- Килди авылының Үзәк урамы буенча юлга вак таш салу;
- Олан авылы зиратына кадәр вак таш җәю.

ЮК ӘЙЕ".

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин